ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2023 п.г.т. Алексеевское № 175

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 19 апрелендәге №137 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга бюджеттан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Федераль әһәмияттәге шәһәрдә Мәскәүдә, Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.03.2019 ел №322 «Субсидияләр рәвешендә, шул исәптән конкурс нигезендә бирелә торган грантлар бирү тәртибен билгеләүче норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» карары нигезендә

**карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 19 апрелендәге №137 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга бюджеттан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. пункт 2.2. 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Конкурс кысаларында 5 җиңүче билгеләнәчәк.»;

1.2. абзац 6 пункт 3.2. 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризалар Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми порталында http://alekseevskiy.tatarstan.ru конкурс уздыру турында игълан урнаштырылган көннән башлап, календарь көннәрендә исәпләнә торган 15 көн

эчендә кабул ителә.»;

1.3. пункт 5.4. 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасы буенча иң зур әһәмият җыйган 5 гариза конкурста җиңүче дип таныла. Гомуми приз фонды 500 мең сум, һәр җиңүчегә 100 мең сум.».

1.4. пункт 6.3. 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Конкурста җиңүче грантны максатчан билгеләнү буенча гаризага ярашлы куллана.

Грант түбәндәге чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә бирелә:

- һөнәри керемгә салым түләүчеләрнең һөнәри эшчәнлеге белән турыдан-туры бәйле җиһазлар һәм техника сатып алу;

- шәхси ярдәмче хуҗалыкны үстерү (авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын үрчетү максатыннан сатып алу, терлекчелек биналары төзү)».

Грантның максатчан билгеләнешен үзгәртү рөхсәт ителми.».

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 19 апрелендәге №137 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетыннан «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга бюджеттан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» карарының 3 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

сүзләр: «Гайнуллин О.А. – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе»

сүзләренә алмаштырырга: «Гайсин М.Р. – Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**